ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2017 ел № 7541

Башкарма комитетның 2016 елның 1 ноябрендәге 5731 номерлы карары белән расланган «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә мәдәниятне үстерү» программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Шәһәр Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 1 ноябрендәге 5731 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 13 сентябрендәге 5406 номерлы карары редакциясендә) расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә мәдәниятне үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 бүлектә «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның мәдәниятләрен саклау һәм үстерү» ярдәмче программасында «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендәге «Барлыгы» юлында «3845,8» цифрларын «3895,8» цифрларына, шул ук бүлекнең «2017 ел» графасында» «1238,8» цифрларын «1288,8» цифрларына алмаштырырга;

2) 8 бүлектә «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның мәдәниятләрен саклау һәм үстерү» ярдәмче программасында «Шәһәр территориясендә яшәүче халыкларның мәдәниятләрен саклауга һәм үстерүгә, аларның рухи бергәлеген ныгытуга, мәдәни региональара һәм халыкара элемтәләрне үстерүгә юнәлдерелгән үткәрелгән чаралар саны» пунктындагы «финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум)

«2017» графасында «1238,8» цифрларын «1288,8» цифрларына алмаштырырга;

3) 8 бүлектә «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның мәдәниятләрен саклау һәм үстерү» ярдәмче программасының «Шәһәр конкурслары, фестивальләр, күргәзмәләр, календарь бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрү» пунктындагы «финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) «2017» графасында «929,4» цифрларын «979,4» цифрларына алмаштырырга;

4) 8 бүлектә «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның мәдәниятләрен саклау һәм үстерү» ярдәмче программасында «ярдәмче программа буенча барлыгы – 7, шул исәптән» юлында «1238,8» цифрларын «1288,8» цифларына алмаштырырга;

5) 8 бүлектә «2017-2019 елларга мәдәни мирас объектларын саклау һәм популярлаштыру» ярдәмче программасында «Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендәге «Барлыгы» юлында «180,0» цифрларын «130,0» цифларына алмаштырырга, шул ук бүлекнең «2017 ел» графасында «80,0» цифрларын «30,0» цифларына алмаштырырга;

6) 8 бүлектә «2017-2019 елларга мәдәни мирас объектларын саклау һәм популярлаштыру» ярдәмче программасында «Канәгатьләнерлек хәлдә булган мәдәни мирас объектлары саны (капиталь ремонт һәм реставрация үткәрү таләп ителми)» пунктының «финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум)» «2017» графасында «50,0» цифрларын «0,0» цифларына алмаштырырга;

7) 8 бүлектә «2017-2019 елларга мәдәни мирас объектларын саклау һәм популярлаштыру» ярдәмче программасында «Ярдәмче программа буенча барлыгы – 8, шул исәптән» юлында «80,0» цифрларын «30,0» цифларына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев